ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06.04.2020 ел Баулы шәһәре №75

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 15 мартындагы 66 номерлы карары белән расланган Муниципаль торак фондының торак биналарын гражданнарга милек итеп тапшыру буенча документларны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

2020 елның 1 мартында кабул ителгән 35-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына ана (гаилә) капиталы средстволарын куллануга бәйле мәсьәләләр буенча үзгәрешләр кертү турында»гы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Муниципаль торак фондының торак биналарын гражданнарга милек итеп тапшыру буенча документларны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 15 мартындагы 66 номерлы карарына 24нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2нче «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендә:

2.5 пунктта 7) пунктча үз көчен югалткан дип танырга; 8), 9 пунктчаларны 7), 8) пунктчалар дип санарга;

Административ регламентка 1нче кушымтада:

6) пунктча үз көчен югалткан дип танырга; 7), 8) пунктчаларны 6), 7) пунктчалар дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны "Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы" МКУ җитәкчесенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров